| | |
|---|---|
| **РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**<br>**СОВЕТ АЗАЛАКОВСКОГО**<br>**СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ**<br>**САРМАНОВСКОГО**<br>**МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА** | **ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**<br>**САРМАН МУНИЦИПАЛЬ**<br>**РАЙОНЫ АЗАЛАК АВЫЛ**<br>**ҖИРЛЕГЕ МУНИЦИПАЛЬ**<br>**БЕРӘМЛЕГЕ** |

РЕШЕНИЕ КАРАР

25 нче март 2024 ел № 3

Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Азалак авыл җирлегендә муниципаль хезмәт турында нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

«Россия Федерациясе дәүләт хезмәте системасы турындагы «Федераль законның 12 статьясына һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында» 2023 елның 12 декабрендәге 594-ФЗ номерлы Федераль законның 6 статьясындагы 1 пунктына, Сарман муниципаль районының «Азалак авыл җирлеге муниципаль берәмлеге» Уставына нигезләнеп, Азалак авыл җирлеге Советы карар итте:

1. Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Азалак авыл җирлегендә муниципаль хезмәт турында нигезләмәгә, Сарман муниципаль районы Азалак авыл җирлеге Советының 2022 елның 14 февралендәге 34 номерлы карары белән расланган түбәндәге үзгәрешне кертергә:

1) 5.5 пунктны 13 пункт белән тулыландырырга) түбәндәге эчтәлектәге:

«13) яллаучының (эш бирүченең) вәкиленә әлеге Федераль законның 15_2 статьясында каралган анкетадагы мәгълүматларның аңа билгеле булган үзгәрешләре турында язма рәвештә хәбәр итәргә, яллаучының (эш бирүченең) вәкиле карары буенча үзгәртелгән мәгълүматлардан тыш (алга таба - анкетада булган мәгълүматлар).».

2. Әлеге карарны "Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында" игълан итәргә (PRAVO.TATARSTAN.RU) һәм Татарстан Республикасы «Сарман муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең рәсми сайтында «Интернет»мәгълүмати-телекоммуникация челтәрендә урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үземдә калдырам.

Азалак авыл җирлеге
Советы рәисе И.Г.Габдулгазизов